КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 12 сентябрь г.Казань № 1118

2024 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чираттагы елга Россия Федерациясе субъектларында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 26 июнендәге 1022 номерлы карары, «Татарстан Республикасында яшәү минимумы турында» 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2024 елга Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 14 133 сум, эшкә яраклы халык өчен – 14 133 сум, пенсионерлар өчен – 11 151 сум, балалар өчен – 12 577 сум итеп расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин